**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 16** **27.02.2026 ел**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 167 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм дәүләт хакимияте системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 167 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (11.09.2015 елдан № 207, 30.10.2018 елдан № 128, 21.03.2019 елдан № 147, 18.11.2019 елдан № 168, 30.07.2020 елдан № 186 Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым салына торган объектлар, аларның һәрберсенең бәясе 300 миллион сумнан артып китсә, тәмамланмаган төзелеш объектларыннан, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йортлардан тыш;».

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Дүрт-Мунча авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **Р.Т.Ситдиков**